Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Күл-Черкен төп гомуми белем мәктәбе»

| **«Каралды»** | **«Килешенде»** | **«Раслыйм»** |
|---|---|---|
| Метод берләшмә җитәкчесе: | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары: | Директор |
| ______Ф.Х.Әхмәтҗанова | ______Л.Р.Гибадуллина | ______Р.Р. Хасанов |
| Беркетмә № 1 | | Боерык № 57 |
| «24” август, 2020 нче ел | «24» август, 2020 нче ел | «24» август, 2020 нче ел |

5-9 нчы сыйныфлар өчен туган телдән (татар теле)эш программасы
Төзеделәр: Гиниятуллина Илдия Рифкать кызы
Хаттапова Фарида Сөләйман кызы
Реализацияләү вакыты: 5 ел

Мәктәпнең педагогик киңәшмә утырышында
каралды һәм расланды
Беркетмә № 1
«24” август, 2020 нче ел

**Күл-Черкен авылы**

**2020 ел**

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

- **Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру:
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;
- активлыкка, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртергә, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкару, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

- **Метапредмет нәтиҗәләр:**

  **Танып-белү гамәлләре:**

  - танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
  - укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
  - мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;
  - уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;
  - фикерләүдә логик чылбыр төзү;
  - тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
  - төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;

- **Коммуникатив УУГ**

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлекитү;
- үз фикерен дәлилле белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау, фикер әйтү автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
- иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, күршең белән хезмәттәшлек итү.

- **Регулятив УУГ:**

- дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;

- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;

- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

  - **Предмет нәтиҗәләр:**

- фонетик, сүз төзелеше һәм лексик берәмлекләр белән эш итүне ныгыту;
- орфоэпик һәм орфографик кагыйдәрне үзләштерү, гамәли куллана белү;
- сүзнең лексик мәгънәсен билгели һәм сөйләмдә урынлы куллана белү;
- тел материалы белән логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- исем, фигыль, зат алмашлыкларын табарга өйрәтү, аларның морфологик үзенчәлекләрен һәм җөмләдә кулланылышын аңлау;
- сүз төркемнәрен дөрес язу, аларны сөйләмдә дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү;
- сүзтезмәләрне аера белү, алардагы ияртүче һәм иярүче сүзне билгеләп, бәйләүче чараларны күрсәтү;
- әйтү максаты буенча төрле җөмләләрне аера белү, аларны дөрес интонация белән әйтү, алардан соң тиешле тыныш билгеләре кую осталыгы һәм күнекмәләре
- булдыру;
- сүзләрдән - җөмләләр, җөмләләрдән бәйләнешле текст төзү осталыгы булдыру;
- морфологик, синтаксик анализ ясау элементларын үзләштерү;
- телдән һәм язма сөйләмне синонимнар, фразеологизмнар белән баету, бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрдән дөрес файдалана белү, сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен урынлы куллану;
- төрлетелләрдәнкергәнсүзләрнеңмәгънәләренаңлапкулланауһәмдөресәйтүкүнекмәләребулдыру;
- сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыруны дәвам итү;
- телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру.

## «ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)» ФӘНЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

**Татар теле турында гомуми мәгълүмат.**

Аралашу чарасы буларак тел. Телнең төп функцияләре. Кеше тормышында һәм үсешендә туган телнең роле.

Тугандаш һәм тугандаш булмаган телләр. Татарлар яши торган регионнар. Кеше һәм җәмгыять тормышында телнең роле.

**Фонетика һәм орфоэпия**.

Лингвистика бүлеге буларак фонетика һәм орфоэпия. Сөйләм органнары, сөйләм авазлары булдыруда аларның урыны. Аваз. Фонема. Татар теленең сузык авазлар системасы, аларның саны. Сузык авазларның классификациясе. Татар теленең сузык авазлар системасындагы үзгәрешләр. Сингармонизм законы, аның төрләре. Сузык авазларның кыскаруы. Дифтонглар. Татар телендә тартыклар, аларның саны. Тартык авазлар классификациясе. Татар теленең тартык авазлар системасындагы үзгәрешләр. Тартыкларның ассимиляциясе, ассимиляция төрләре. Татар һәм рус телләрендә тартык һәм сузык авазлар.

Татар телендә басым. Татар теленең үз сүзләрендә һәм алынмаларда басымның сакланмау очраклары. Интонация төшенчәсе.

Әдәби тел нормалары. Орфоэпия нормалары төшенчәсе. Орфоэпик сүзлек.

Фонетик анализ.

**Графика, орфография.**

Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Татар теле алфавиты.

Орфография. Сузыкларның язылышы. Тартыкларның язылышы. Ике аваз белдерә торган хәрефләрнең язылышы. “ъ” һәм “ь” билгеләренең язылышы.

Орфографик сүзлек. Телнең орфографик нормалары.

**Морфемика (телнең морфем төзелеше) һәм сүз ясалышы.**

Сүзнең барлыкка килүе һәм төзелеше турында гомуми мәгълүмат. Телнең иң кечкенә мәгънәле кисәге буларак морфема. Тамыр һәм аффикс. Тамырдаш сүзләр. Аффикслар ярдәмендә яңа сүз ясау. Аларның төрле сүз төркеменә караган сүзләр ясалышындагы роле.

Аффикслар, аффикс төрләре: сүзъясагыч һәм модаль аффикслар. Тамыр һәм ясалма нигезләр.

Татар телендә сүз ясау ысуллары. Тамыр сүзләр. Ясалма сүзләр, ясалма сүзләрнең структур төрләре: кушма, тезмә, парлы.

Татар һәм рус телләрендә сүз төзелешендәге төп аермалар.

Этимология төшенчәсе.

Сүз ясалышы ягыннан һәм морфемик анализ.

**Лексикология һәм фразеология.**

Телнең төп берәмлеге буларак сүз. Сүзнең лексик берәмлеге. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр. Антонимнар, синонимнар, паронимнар, омонимнар һәм аларның төрләре.

Төрки-татар чыгышлы сүзләр һәм алынмалар.

Татар теленең сүзлек составы: архаизмнар, тарихи сүзләр, неологизмнар һәм аларның төрләре. Диалектизмнар. Терминнар һәм һөнәрчелек сүзләре. Жаргон сүзләр.

Фразеологизмнар, аларның төрләре. Сөйләмдә фразеологизмнарны куллану үзенчәлекләре.

Төрле төрдәге сүзлекләр, аларны төрле эшчәнлектә файдалану.

Татар теленең төп лексик нормалары. Сүзгә лексик анализ ясау.

**Морфология.**

Сүзләрнең лексик-грамматик төрләре буларак сүз төркемнәре. Сүз төркемнәренең классификациясе. Мөстәкыйль, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәре. Аларның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр ясау, аларның семантикасы һәм кулланылыш үзенчәлеге.

Татар теленең төп морфологик нормалары .

Сүзгә морфологик анализ ясау.

**Синтаксис.**

Синтаксис турында гомуми мәгълүмат. Сүзтезмә һәм җөмлә. Җөмләдә синтаксик бәйләнеш. Тезүле һәм ияртүле бәйләнеш.

Җөмлә. Җөмлә кисәкләре, баш һәм иярчен кисәкләр. Җөмләдә сүз тәртибе.

Гади җөмлә төрләре. Җәенке һәм җыйнак җөмләләр. Тулы һәм тулы булмаган җөмләләр. Сөйләмдә бер составлы җөмләләрне куллану үзенчәлеге.

Раслау һәм инкарь җөмләләр турында гомуми мәгълүмат.

Туры һәм кыек сөйләм. Диалог, диалогта тыныш билгеләренең куелышы.

Кушма җөмлә төшенчәсе. Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.

Иярченле кушма җөмлә төшенчәсе. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмлә төзелеше. Синтетик иярченле кушма җөмлә, әлеге төр җөмләләрдә бәйләнеш төрләре, тыныш билгеләре. Аналитик иярченлек кушма җөмлә, бәйләнеш төрләре һәм тыныш билгеләре.

Иярчен җөмләләр, аларның төрләре. Төрле юл белән бәйләнгән кушма җөмләләр.

Текст синтаксисы турында гомуми мәгълүмат.

Телнең төп синтаксик нормалары.

Синтаксик анализ.

**Пунктуация.**

Татар телендә тыныш билгеләре. Ия һәм хәбәр арасында сызык куелу очраклары. Аерымланган иярчен кисәкләр, эндәш һәм кереш сүзләр булган җөмләләрдә тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр булган очракта тыныш билгеләренең куелышы.

Диалог, диалогта тыныш билгеләренең куелышы. Туры сөйләм булган җөмләләрдә тыныш билгеләре.

Кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.

**Стилистика һәм сөйләм культурасы.**

Телдән һәм язма сөйләм төшенчәсе. Сөйләмдә синоним, антоним һ.б. дөрес куллану. Сөйләм культурасын үстерү һәм стильне камилләштерүдә синтаксик синонимнарның роле.

Сөйләм культурасы төшенчәсе. Сөйләм һәм язма әдәби сөйләмгә карата таләпләр турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмдә төрле лексик чаралар (синоним, антоним, калькалар, фразеологик әйтелмәләр, мәкальләр һәм әйтемнәр) куллану мөмкинлеге.

**Тел һәм мәдәният.**

Татар теленең сөйләм этикеты. Коммуникация төренә карап, тиешле сөйләм этикеты нормаларын куллану.

Милли-мәдәни компонентлы мәгънә йөрткән тел берәмлекләрен таный һәм аларның мәгънәләрен аңлатмалы, этимологик, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге һәм башка сүзлекләр ярдәмендә аңлата белү.

**Укыту курсының эчтәлеге 5 класс**

| | |
|---|---|
| Сөйләм һәм аралашу | Аралаша белү – кеше мәдәниятенең әһәмиятле өлеше.<br>Сөйләм һәм аралашу. Сөйләм ситуациясе. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Монолог төрләре: хикәяләү, сурәтләү, фикерләү. |
| **Сөйләм эшчәнлеге** | Эшчәнлек төре буларак сөйләм. Сөйләм эшчәнлеге төрләре: тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу. Аралашу шартларына тәңгәл рәвештә укыган, тыңлаган, күргән мәгълүмат эчтәлеген сайлап алып, кыскача һәм җентекләп сөйләү. Дәреслектә күрсәтелгән сылтамалар буенча Интернет челтәрләрендә мәгълүмат эзләү. |
| **Текст** | Сөйләм эшчәнлеге продукты буларак текст. Текст төшенчәсе. Текст темасы, төп мәгънә. Текст микротемасы. Текст кисәкләре һәм җөмләләрне бәйләүче лексик һәм грамматик чаралар. Текст планы (гади).<br>Хикәяләү (хикәя, сөйләү), сурәтләү (предметне, халәтне), фикерләү, аларның төп үзенчәлеге. |
| Сөйләм теле | Сөйләм телен куллану даирәсе, аралашуның типик ситуацияләре. |
| **Татар теле турында гомуми мәгълүмат.** | Аралашу чарасы буларак тел. Татар теле — татар әдәби әсәрләр теле. Тел турындагы фән буларак лингвистика.<br>Лингвистиканың төп бүлекләре (гомуми мәгълүмат). |

| | |
|---|---|
| Башлангыч сыйныфта үткән материалны кабатлау. | Аваз. Татар теленең сузык авазлар системасы. Сузыкларның язылышы. Тартыкларның язылышы. Телнең орфографик кагыйдәләре. Сүзнең лексик мәгънәсе. Сүз ясалышы һәм сүз формасы үзгәрү. Грамматиканың бер бүлеге буларак морфология. Синтаксис берәмлеге буларак сүзтезмә. Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. Аларның интонацион һәм мәгънәви үзенчәлекләре. |
| Фонетика һәм графика. | Лингвистика бүлеге буларак фонетика. Сөйләм органнары, аларның сөйләм авазлары булдыруда катнашуы. Татар теленең сузык авазлар системасы, аларны күләме.Сузык авазларның классификациясе. Татар теленең сузык авазлар системасындагы үзгәрешләр. Сингармонизм законы, аның төрләре. Сузыкларның кыскаруы. Дифтонглар. Татар телендә тартыклар, аларның күләме. Татар теленең тартыклар системасындагы үзгәрешләр. Тартыклар ассимиляциясе, ассимиляция төрләре. Татар һәм рус телләрендә сузык һәм тартык авазлар. Интонация төшенчәсе. Татар телендә басым. Татар теленең үз сүзләрендә һәм алынмаларда басым сакланмау очраклары. Сүз формаларында басым куюның авыр очраклары. |
| Орфоэпия һәм орфография. | Әдәби тел нормалары. Орфоэпия нормалары төшенчәсе. Орфоэпик сүзлек. Фонетик анализ.<br>Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Татар теле алфавиты. Орфография. Сузыкларның язылышы. Тартыкларның язылышы. Ике авазны белдерә торган хәрефләрнең язылышы. “ъ” һәм “ь” билгеләренең язылышы.<br>Орфографик сүзлек.Телнең орфографик нормалары.<br>Кабатлау. |
| **Лексикология һәм фразеология** | Лингвистиканың бер бүлеге буларак лексикология.<br>Телнең төп берәмлеге буларак сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе. Антоним, синоним, пароним, омонимнар һәм аларның төрләре.<br>Татар теленең үз сүзләре һәм алынмалар.<br>Татар теленең сүзлек составы. Актив һәм пассив лексика. Искергән сүзләр һәм неологизмнар.<br><br>Фразеологизмнар, аларның мәгънәләре. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрне куллану үзенчәлекләре.<br>Төрле төр сүзлекләр, аларны төрле эшчәнлек вакытында файдалану.<br>Татар теленең төп лексик нормалары.<br>Сүзгә лексик анализ ясау.<br>Мәкальләр, әйтемнәр. |
| **Морфемика һәм сүз ясалышы** | Лингвистиканың бер бүлеге буларак морфемика. |

| | |
|---|---|
| | **Морфемика (телнең морфемик төзелеше) һәм сүз ясалышы.** Сүз төзелеше һәм ясалышы турында гомуми мәгълүмат. Телнең иң кечкенә берәмлеге буларак морфема. Тамыр һәм аффикс. Тамырдаш сүзләр. Аффикслар ярдәмендә яңа сүзләр ясалышы. Төрле сүз төркеменә караган сүзләр ясалышында аффиксларның роле.<br>Аффикслар, аффикс төрләре: сүз ясагыч, форма ясагыч һәм бәйләгеч аффикслар.<br>Татар телендә сүз ясау формалары. Тамыр сүзләр. Ясалма сүзләр. Кушма сүзләр, кушма сүзләрнең структур төрләре: кушма, тезмә, парлы сүзләр. Татар һәм рус телләрендә сүз төзелешендәге төп аермалар. Морфемик анализ һәм сүз ясагыч анализ. |
| **Морфология** | Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре.<br>Сүз төркеме буларак исем, аның гомуми мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре.<br>Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр.<br>Сүз төркеме буларак сыйфат, аның гомуми мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функциясе. Сүз төркеме буларак фигыль, аның гомуми мәгънәсе, синтаксик функцияләре.<br>Фигыльләрнең төрләнеше.<br>Кабатлау. |
| **Синтаксис** һәм **пунктуация** | Грамматиканың бер бүлеге буларак синтаксис.<br>Синтаксик берәмлеге буларак сүзтезмә.<br>Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге буларак җөмлә.<br>Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре: хикәя, боерык (тойгылы) һәм сорау җөмләләр.<br>Эндәш сүзләр, аларның функцияләре.<br>Әңгәмәдәшкә йогынты ясау, сөйләмгә бәя бирү чагылышы буларак кереш конструкцияләр (сүзләр, сүзтезмәләр).<br>Җөмлә азагында тыныш билгеләре. Гади җөмләдә тыныш билгеләренең куелышы белән бәйле пунктуация кагыйдәләре.<br>Кабатлау. |
| Стилистика һәм сөйләм культурасы | Телдән һәм язма сөйләм турында төшенчә. Сөйләмдә синоним, антоним һ.б. урынлы куллану. Сөйләм культурасы үсеше һәм стильләрне камилләштерүдә синтаксик синомнарның роле.<br>Әдәби тел төшенчәсе. Телдән һәм язма әдәби телгә карата куелган таләпләр турында гомуми төшенчә.<br>Сөйләмдә төрле лексик чараларны (синоним, антоним, калька, фразеологик әйтелмәләр, мәкальләр һәм әйтемнәр) куллану мөмкинлеге.<br>Төрле жанр һәм стильгә караган текстлар белән эшләү. Текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. |

| | |
|---|---|
| **Сөйләм культурасы** | Лингвистиканың бер бүлеге буларак сөйләм культурасы. Тел нормалары, аның функцияләре. Әдәби телнең төп кагыйдәлере: орфоэпик, лексик, грамматик, дөрес язу кагыйдәләре. Кагыйдә вариантлары. Сөйләм хаталары. Татар теленең һәм сөйләм культурасының лексик байлыгы. Татар теленең сөйләм этикеты. Коммуникация төренә карап сөйләм этикетының тиешле кагыйдәләрен куллану. Татар сөйләм этикеты: исәнләшү, саубуллашу, котлау ситуацияләре этикеты. Диалогларда аралашу – эш-хәрәкәткә өйдәү. Телдә халык мәдәнияте һәм тарихы чагылышы.<br>Фольклор һәм әдәби әсәрләрдә милли-мәдәни компонентлы тел берәмлекләре. |
| **Тел һәм мәдәният** | Телдә татар халкының тарихы, мәдәнияте һәм Россиядә яшәүче башка халыклар белән бәйләнешенең чагылышы.<br>Текстта милли-мәдәни компонентлы мәгънәгә ия булган тел берәмлекләрен билгеләү һәм аларның мәгънәләрен аңлатмалы, этимологик, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге  һ.б. сүзлекләр ярдәмендә аңлата белү. |

**6 класс**

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| Сөйләм һәм аралашу | Аралашу шартлары. Монолог төрләре: хикәяләү, сурәтләү, фикерләү. Сораштыру диалогы, диалог – эш-хәрәкәткә чакыру, этәргеч. Төрле төр диалоглар тыңдәшлеге. |
| **Сөйләм эшчәнлеге** | Сөйләм эшчәнлеге төрләре буларак тыңлап аңлау, уку, язуның төп үзенчәлекләре.  Сайлап алу, танышу, детальле тыңлап аңлау. Телдән сөйләнә торган монологны аңлау эффиктивлыгын арттыра торган ысуллар. Уку культурасы. Телдән сөйләүнең төп үзенчәлекләре. Күргән, ишеткән мәгълүматны аралашу шартлары буенча кыскартып, сайлап алып, җентекләп сөйләү.  Язма сөйләмнең төп үзенчәлекләре. Укылган, тыңланылган текстны тулы, кыскача, сайлап алып язу. |
| **Текст.** | Текстның төп үзлекләре. Текст структурасы. Текстның мәгънәви, композицион бөтенлеге һәм төзеклеге. Тема, тексттагы төп фикер. Текстның микротемасы. Текст өлешләрен һәм җөмләләрне үзара бәйли торган лексик, грамматик һәм мәгънәви чаралар. Тексттагы төп һәм өстәмә мәгълүмат. План (катлаулы), аннотация. Сөйләмнең функциональ-мәгънәви тибы буларак сурәтләү, аның үзенчәлекләре (предмет, халәт, |

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| | процесны сурәтләү); сөйләмнең башка функциональ-мәгънәви кисәкләре белән тыңдәшлеге. |
| **Телнең функциональ төрлелеге.** | Телнең функциональ төрлелеге: гади сөйләм, рәсми стиль, фәнни стиль, публицистик стиль.<br>Гади сөйләмгә хас булган тел-сурәтләү чаралары, сөйләм максаты, типик сөйләм ситуацияләре, кулланылу даирәсе.<br>Гади сөйләмнең төп жанрлары: хикәя, әңгәмә.<br>Рәсми стильгә хас булган тел-сурәтләү чаралары, сөйләм максаты, типик сөйләм ситуацияләре, кулланылу даирәсе. Рәсми стильнең төп жанрлары: гариза, аның үзенчәлекләре.<br>Фәнни стильнең төп жанрлары: аннотация, аның үзенчәлекләре.<br>Публицистик стильнең төп жанрлары: чыгыш, аның үзенчәлекләре. |
| **Тел турында гомуми мәгълүмат** | Хәзерге татар теленең кулланылыш формалары: әдәби тел, территориаль диалектлар, шәһәр гади сөйләме, билгеле бер һөнәр ияләренә хас булган сөйләм, жаргон |
| **Фонетика һәм графика.** | Сөйләмдә авазлар үзгәреше. Аваз һәм фонема. Татар теленең сузыклар системасы, аларның күләме. Сузык авазлар классификациясе. Татар теленең тартыклар системасындагы үзгәрешләр. Тартыклар ассимиляциясе, ассимиляция төрләре. Татар һәм рус телләрендә сузык һәм тартык авазлар.<br>Татар телендә басым. Татар теленең үз сүзләрендә һәм алынмаларда басым сакланмый торган очраклар.<br>Интонация төшенчәсе.<br>Фонетик анализ.<br>Кабатлау. |
| **Орфоэпия һәм орфография** | Орфоэпия нормалары турында төшенчә.<br>Орфоэпик сүзлек.<br>Графика һәм орфографика турында төшенчә. Телнең орфографик нормалары.<br>Баш һәм юл хәрефләрне куллану. Сүзне юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре.<br>Сузыкларның дөрес язылышы.<br>Тартыкларның дөрес язылышы.<br>Сүзләрнең бергә, аерым һәм сызыкча аша язылу очракларына бәйле орфографик кагыйдәләр.<br>Орфографик сүзлек. |
| **Лексикология һәм фразеология** | Лексикология. Тел берәмлеге буларак сүз. Сүзнең башка тел берәмлекләреннән аермасы. Татар теленең сүзлек составы: искергән сүзләр, тарихи сүзләр, неологизмнар һәм аларның төрләре.<br>Диалекталь сүзләр. Терминнар һәм һөнәрчелек сүзләре. Жаргон лексикасы һәм аларның кулланылыш үзенчәлекләре. Сүзнең стилистик бизәлеше.<br>Фразеологик әйтелмәләр, аларның мәгънәләре. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрне куллану үзенчәлекләре. |

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| | Төрле сүзлекләр, аларны төрле эшчәнлектә файдалану.<br>Сүзгә лексик анализ ясау. Кабатлау. |
| **Морфемика һәм сүз ясалышы** | Сүз ясалышы һәм сүз формасы үзгәрү, сүз ясагыч, форма ясагыч һәм бәйләгеч аффикслар.<br>Сүз ясалыш пары, сүз ясалыш чылбыры. Сүз ясалыш оясы.<br>Сүз ясалышының төп ысуллары.<br>Аффикслар ярдәмендә сүз ясалышы.<br>Сүзъясалыш ысулы буларак, сүзләрне кушу. Кушма сүзләр. Сүзләргә морфемик һәм сүз ясагыч анализ ясау.<br>Кабатлау. |
| **Морфология** | Грамматиканың бер бүлеге буларак морфология.<br>Сүз төркемнәре классификациясе. Мөстәкыйль, хәбәрлек һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәре.<br>Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре.<br>Сүз төркеме буларак  исем (кабатлау). Сан, килеш һәм тартым категорияләре.<br>Сүз төркеме буларак, сыйфат (кабатлау). Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфат дәрәҗәләре.<br>Сүз төркеме буларак сан, аның гомумкатегория мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре. Саннарның мәгънә ясалыш ягыннан сан төркемчәләре.<br>Микъдар һәм тәртип саннарының грамматик үзлекләре.<br>Сүз төркеме буларак алмашлыклар, аларның гомумкатегория мәгънәләре, морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре. Мәгънә һәм грамматик билгеләр буенча алмашлык төркемнәре. Алмашлыкларның төрләнеше.<br>Сүз төркеме буларак фигыль, аның гомумкатегория мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре. Фигыльләрнең төрләнеше. Затланышлы фигыль формалары:  хикәя фигыль, боерык фигыль, теләк фигыль, шарт фигыль.<br>Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау. |
| Синтаксис һәм пунктуация | Грамматиканың бер өлеше буларак синтаксис.<br>Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге буларак җөмлә. Эмоциональ бизәлеш ягыннан җөмлә төрләре: тойгысыз һәм тойгылы җөмлә. Аларның интонацион һәм мәгънәви үзенчәлекләре. Җөмләнең грамматик нигезе.<br>Гади һәм кушма җөмләләр.<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре: аергыч, тәмамлык, хәл.<br>Җәенке һәм җыйнак җөмләләр.<br>Тиңдәш кисәкле җөмләләр.<br>Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә бәйләүче чаралар.<br>Эндәш сүз, аның функцияләре.<br>Эндәш сүзле җөмләдә басым.<br>Татар телендә тыныш билгеләре.Кабатлау. |

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| Стилистика һәм сөйләм культурасы | Сөйләмдә синоним, антонимнарны урынлы куллану.<br>Сөйләм культурасын үстерүдә һәм стильләрне камилләштерүдә синтаксик синонимнарның роле.<br>Сөйләмдә төрле лексик чараларны (синоним, антоним,калька, фразеологик әйтелмә, мәкаль, әйтем) куллану мөмкинлеге.<br>Төрле жанр һәм стильдәге тектслар белән эшләү. Текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. |
| **Сөйләм культурасы** | Лингвистиканың бер өлеше буларак сөйләм культурасы.<br>Телдән аралашу этикасы, эффективлыгы, нормативлыгына ирешүнең мәҗбүри шарты буларак, аралашу шарты һәм даирәсе нигезендә тел-сурәтләү чараларын сайлау.<br>Алмашлык, сан, фигыльләрне куллануның орфоэпик, лексик, грамматик, стилистик кагыйдәләре һәм язылыш нормалары. Кагыйдә вариантлары.<br>Хәзерге татар теленең норматив сүзлекләре (орфоэпик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, орфографик сүзлек), аларның хәзерге татар әдәби телен үзләштерүдәге роле. |
| **Тел һәм мәдәният** | Тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнеше. |

## 7 сыйныф

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| **Сөйләм һәм аралашу** | Сөйләм этикеты һәм аралашу кагыйдәләре. Аралашу чарасы буларак тел. Сөйләм шартлары. Монолог төрләре: хикәяләү, сурәтләү, фикерләү.<br>Сораштыру диалогы, диалог – эш-хәрәкәткә чакыру, этәргеч. Төрле төр диалоглар тыңдәшлеге.<br>Сөйләм төрләре: кеше халәтен сурәтләү.<br>Композицион формалар: газета язмасы, реклама, портретны сурәтли торган очерк. |
| **Сөйләм эшчәнлеге** | Сөйләм эшчәнлеге төрләре буларак тыңлап аңлау, уку, язуның төп үзенчәлекләре. Телдән һәм язма сөйләм формалары тәңгәллеге. Телдән сөйләнә торган монологны аңлау эффиктивлыгын арттыра торган ысуллар. Уку культурасы. Телдән сөйләүнең төп үзенчәлекләре.<br>Сөйләү – сөйләм этәргече. |
| **Текст** | Сөйләм эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак текст. Текстның төп билгеләре: кисәкләргә бүленә алу сәләте, мәгънәви бөтенлек, формаль яктан бәйләнгән булу, әйтемнең автономлыгы.<br>Тема, тексттагы төп фикер. Текстның микротемасы, текст планы; текстның абзацларга бүленеше: кереш, төп өлеш, йомгак. |

| | |
|---|---|
| **Телнең функциональ төрлелеге.** | Сөйләмнең типик ситуацияләре, кулланылу даирәсе, сөйләм максаты, гади сөйләмгә хас булган тел-сурәтләү чаралары.<br>Рәсми стиль сөйләменең типик ситуацияләре, кулланылу даирәсе, сөйләм максаты, рәсми стильгә хас булган тел-сурәтләү чаралары.<br>Рәсми стильнең төп жанрлары: гариза, аның үзенчәлекләре.<br>Фәнни стильнең төп жанрлары: аннотация, аның үзенчәлекләре.<br>Публицистик стильнең төп жанрлары: чыгыш, аның үзенчәлекләре. |
| **Төрки телләр арасында татар теле** | Сөйләм чарасы буларак тел. Татар теле һәм аның төрки телләр арасындагы урыны. Төрки телләргә хас булган үзлекләр. Идел-Урал буе регионы. |
| **Фонетика һәм графика.** | Фонетиканың өйрәнү предметы.<br>Сөйләм авазлары. Фонетик иҗек. Басым һәм аның үзенчәлекләре. Интонация төшенчәсе. Алынма сүзләрнең әйтелеше. Аваз һәм хәреф тәңгәллеге. Фонетик анализ. |
| **Орфоэпия һәм орфография** | Орфоэпия нормалары турында төшенчә. Графика һәм орфографика турында төшенчә.Орфографик сүзлек. |
| **Лексикология һәм фразеология** | Лексиканың өйрәнү предметы.Сүз һәм аның лексик мәгънәсе.<br>Сүзнең лексик мәгънәсен аңлатуның төп ысуллары: сүзлектәге кыскача аңлатма; синоним, антоним, тамырдаш сүзләр табу.<br>Үзенчәлекле лексик төркем буларак этикет сүзләре.<br>Аңлатмалы сүзлек белән танышу һәм аны сөйләм практикасында куллану.<br>Сүзнең лексик мәгънәсе, морфемик төзелеше һәм язылышы арасындагы бәйләнеш.<br>Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр.<br>Әдәби троплар: метафора, җанландыру, эпитет хасил итү ысулы буларак сүзнең күчерелмә мәгънәсе.<br>Фразеологик әйтелмәләр һәм аларның мәгънәсе.<br>Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрнең кулланылыш үзенчәлекләре.<br>Сүзгә лексик анализ ясау.Кабатлау. |
| **Морфемика һәм сүз ясалышы** | Морфемиканың өйрәнү предметы.<br>Телнең иң кечкенә берәмлеге буларак морфема. Сүз ясагыч, форма ясагыч һәм бәйләгеч аффикслар.Тамыр, тамырдаш сүзләрнең мәгънәви бөтенлеге. Сүз нигезе. Сүз формасын хасил итә торган морфема буларак кушымча.<br>Морфемика һәм орфография арасындагы бәйләнеш.<br>Сүзгә морфемик һәм сүз төзелеше ягыннан анализ ясау. |
| **Морфология** | Грамматиканың бер бүлеге буларак морфология.<br>Сүз төркемнәре классификациясе.<br>Мөстәкыйль сүз төркемнәре: рәвеш, фигыль, аваз ияртемнәре һәм аларның үзенчәлекләре. Төрләнләндерү.Модаль кисәкләр (кисәкчә, ымлык, предикатив сүзләр)Хәбәрлек сүз төркеме (бәйлекләр һәм теркәгечләр).<br>Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр. Сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив.Сыйфат фигыль, аның грамматик үзлекләре. Сыйфат фигыльдә фигыль һәм сыйфат билгеләре.Хәзерге, үткән һәм киләчәк заман сыйфат фигыль.Сыйфат фигыльнең синтаксик функцияләре.<br>Хәл фигыль, аның грамматик үзлекләре. Хәл фигыльдә рәвеш һәм фигыль билгеләре. Хәл фигыльнең синтаксик функцияләре.<br>Сүзгә морфологик анализ ясау. Кабатлау. |

| | |
|---|---|
| **Синтаксис һәм пунктуация** | Грамматиканың бер өлеше буларак синтаксис.<br>Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге буларак җөмлә.<br>Җөмләнең баш кисәкләре буларак, ия һәм хәбәр.<br>Иянең белдерелү ысуллары. Гади һәм тезмә хәбәр. Ия һәм хәбәр арасына сызык куелу.Җөмләнең иярчен кисәкләре буларак аергыч, тәмамлык һәм хәбәр.<br>Аергыч төрләре.Хәл төрләре.<br>Аерымлану төшенчәсе. Аергыч, тәмамлык һәм хәлләрнең аерымлануы.<br>Җөмләнең аныклаучы кисәкләре. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.<br>Иясе генә булган һәм хәбәре генә булган бер составлы җөмләләр.<br>Эндәш һәм кереш сүзләр булган җөмләләр.<br>Гади җөмләгә синтаксик анализ ясау.Татар телендә тыныш билгеләре.<br>Пунктуацион-мәгънәви өлеш.Татар теленең пунктуацион кагыйдәләре. Кабатлау. |
| **Стилистика һәм сөйләм культурасы** | Сөйләмдә синоним, антонимнарны урынлы куллану.<br>Сөйләм культурасын үстерүдә һәм стильләрне камилләштерүдә синтаксик синонимнарның роле.<br>Сөйләмдә төрле лексик чараларны (синоним, антоним, калька, фразеологик әйтелмә, мәкаль, әйтем) куллану мөмкинлеге.<br>Төрле жанр һәм стильдәге текстлар белән эшләү. Текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. |
| **Сөйләм культурасы** | Кыскартылма сүзләрне дөрес куллану.<br>Сөйләмдә исем, сыйфат һәм фигыльләрне дөрес һәм сәнгатьле әйтү.<br>Әдәби әсәрләрдә исем, сыйфат һәм фигыльләрнең кулланылышын күзәтү.<br>Хәзерге татар теленең норматив сүзлекләре (орфоэпик, аңлатмалы, орфографик, грамматик бәхәс уята торган мәсьәләрне хәл итә торган сүзлек), аларның хәзерге татар әдәби теле нормаларын үзләштерүдәге роле. |
| **Тел һәм мәдәният** | Мәдәният көзгесе буларак тел. Тел һәм мәдәният арасындагы бәйләнеш. Мәдәният һәм милли тел үзенчәлекләре. |

## 8 сыйныф

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| Сөйләм һәм аралашу | Аралаша белү – кеше мәдәниятнең иң мөһим өлеше. Текст, стиль һәм сөйләм төрләре турында өйрәнгәнне кабатлау; өйрәнгән сөйләм стильләренә хас булган тел-сурәтләү чаралары турындагы күзаллауны киңәйтү. |
| **Сөйләм эшчәнлеге** | Эшчәнлек төре буларак сөйләм.<br>Сөйләм төрләре: тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу. Тыңлап аңлау төрләре: сайлап алып, танышу. Танышу, өйрәнү, эзләү, уку төрләре стратегиясе. Текстның мәгънәсенә төшенеп уку. Аралашу шартларына туры китереп, укылган, тыңланган текстны тулы, кыскача, сайлап алып язу. |
| **Текст** | Тексттагы фикерне дәвам итү: җөмләләрнең тезүле һәм ияртүле бәйләнеш ысуллары, бәйләү чарасы - хәл фигыль.<br>Кабатлауның тексттагы роле: җөмләләрне бәйләү ысулы, сөйләмнең сәнгатьлелеген камилләштерә торган стилистик чара буларак норматив кабатлау һәм кабатлау – җитешсезлек. |

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| **Сөйләм стильләре** | Фәнни һәм рәсми стиль (куллану даирәсе, аралашу максаты, шул стильләргә хас булган тел-сурәтләү чаралары).<br>Фәнни стильгә хас булган текст фрагментлары (фән төшенчәсен аңлату, фәнни төшенчәләрнең классификациясе), дефиниция күренешенең тел чаралары һәм структурасы.<br>Рәсми стильгә хас булган композицион формалар (жанрлар) – күрсәтәмә, игълан. |
| Тел – аралашуның иң мөһим чарасы. | Аралашу чарасы буларак тел. Татар теле һәм аның башка телләр арасындагы урыны. |
| **Фонетика һәм графика.** | Фонетиканың өйрәнү предметы. Сөйләм авазлары. Фонетик иҗек. Фонетик транскрипция элементлары. Татар телендә басым төшү үзенчәлекләре. Сүзгә фонетик анализ ясау.<br>*е, ё, я, ю* авазларының мәгънәсе.<br>Кабатлау. |
| **Орфоэпия һәм орфография** | Орфографик сүзлек һәм аны сөйләм практикасында куллану.<br>Орфографиянең өйрәнү предметы.<br>Орфограмма төшенчәсе. |
| **Лексикология һәм фразеология** | Әдәби троплар: метафора, җанландыру, эпитет хасил итү ысулы буларак сүзнең күчерелмә мәгънәсе.<br>Синоним, антоним сүзләр. Омонимнар.<br>Татар теленең сүзлек запасын тутыру ысуллары. Төрки-татар сүзләре һәм алынмалар.<br>Фразеологик әйтелмәләр һәм аларның стилистик үзлекләре, сөйләмдәге төп функцияләре.Кабатлау. |
| **Морфемика һәм сүз ясалышы** | Лингвистиканың бер бүлеге буларак морфемика. Сүзнең иң кечкенә берәмлеге буларак морфема. Сүзнең ясалышы һәм үзгәреше. Тамырдаш сүзләр. Мөстәкыйль сүзләрнең тамыры һәм кушымча.<br>Татар теленең сүзлек запасын тутыру ысуллары: сүз ясалыш һәм башка телләрдән кергән алынмалар.<br>Татар телендә сүз ясалышы механизмы төшенчәсе. Сүз ясалышының төп ысуллары.<br>Сүзгә морфемик һәм сүз ясагыч анализ. Кабатлау. |
| **Морфология** | Татар теленең төп морфологик кагыйдәләре. Сүзләрнең лексик-грамматик төрләре буларак, сүз төркемнәре. Мөстәкыйль, хәбәрлек һәм модаль сүз төркемнәр.<br>Хәбәрлек сүз төркеме: бәйлек һәм теркәгечләр.<br>Модаль сүз төркемнәре: ымлык, кисәкчә, предикатив сүзләр. Аларның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре.<br>Төрле сүз төркемнәренә караган сүзләрнең ясалышы, аларның семантикасы һәм кулланылыш үзенчәлекләре.<br>Сүзгә морфологик анализ ясау. |

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| Синтаксис һәм пунктуация | Туры һәм кыек сөйләм. Чит сөйләмне җиткерү ысуллары: туры һәм кыек сөйләм. Туры сөйләм белән җөмлә төзелеше. Туры сөйләм вакытында тыныш билгеләренең куелышы. Чит сөйләмне җиткерү ысулы буларак цитата. Цитатаны тыныш билгеләре белән билгеләү. Диалог.<br><br>Кушма җөмлә төшенчәсе. Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.<br><br>Иярченле кушма җөмлә. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмлә төзелеше. Синтетик иярченле кушма җөмлә, әлеге төр җөмләдә җөмләләрнең үзара бәйләнеше, тыныш билгеләре. Аналитик иярченле кушма җөмлә, әлеге төр җөмләдә җөмләләрнең үзара бәйләнеше, тыныш билгеләре.<br><br>Иярчен җөмлә, аның төрләре. Төрле төр бәйләү чаралары булган кушма җөмләләр.<br>Иярченле кушма җөмләнең төзелеше: баш һәм иярчен җөмлә; иярченле кушма җөмләдә бәйләү чаралары.<br>Баш һәм иярчен җөмләләр арасында тыныш билгеләре.<br>Татар телендә тыныш билгеләре. Пунктуацион-мәгънәви өлеш. Татар теленең пунктуацион кагыйдәләре.Кабатлау. |
| Стилистика һәм сөйләм культурасы | Сөйләмдә, фикерне төгәлрәк җиткерү, бер үк сүзләрне кабатламау өчен, синоним исемнәрне куллана белү сәләте.<br>Сөйләмдә, фикерне төгәлрәк җиткерү, бер үк сүзләрне кабатламау өчен, синоним фигыльләрне куллану.<br>Төрле жанрдагы һәм стильдәге текстлар белән эшләү. Текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. |
| **Сөйләм культурасы** | Сөйләмдә рәвешләрнең һәм фигыльләрне дөрес, урынлы куллану.<br><br>Әдәби сөйләмдә хәбәрлек һәм модаль сүз төркемнәренең кулланылышын күзәтү.<br><br>Хәзерге татар теленең норматив сүзлекләре (орфоэпик, аңлатмалы, орфографик сүзлек), хәзерге татар әдәби телен үзләштерүдә аларның роле. |
| **Тел һәм мәдәният** | Телдә татар халкының тарихы һәм мәдәнияте, аның Россиядә яшәүче башка халыклар белән бәйләнешенең чагылышы.<br>Традицион татар көнкүреше предметын атаучы лексика, искергән сүзләр, фольклор лексикасы һәм фразеологик әйтелмәләр.<br>Татар мәкальләре һәм әйтемнәре.<br>Татар телендә татар халкының һәм башка халыкларның материаль һәм рухи кыйммәтләре чагылышы. |

**9 класс**

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| Сөйләм һәм аралашу | Аралашу ситуациясе һәм аның компонентлары: катнашучылар һәм аралашу шартлары; шәхси һәм шәхси булмаган сөйләшү, рәсми һәм рәсми булмаган, алдан әзерләнгән һәм әзерләнмәгән аралашу. Типик ситуацияләргә хас булган аралашу кагыйдәләрен үзләштерү. |
| **Сөйләм эшчәнлеге** | Сөйләм эшчәнлеге төрләре һәм аларның үзенчәлекләре. Уку: китап һәм башка чыганаклар (шул исәптән ММЧ, Интернет чыганаклары) белән эшләү культурасы, алар белән эшләү үрнәкләре.<br>Сөйләүченең коммуникатив максатларын тыңлап аңлау, төрле текстларны тыңлап аңлау, текстның мәгънәви кисәкләрен билгеләү һәм алар арасындагы бәйләнешне табу.<br>Сөйләү. Диалогларда катнашу.<br>Язу. Тыңланган яки укылган мәгълүматның эчтәлеген язма формада тапшыра белү. Инша, бәяләмә һәм рецензия язу. |
| **Текст** | Сөйләм эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак текст. Аның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. Тема, текстның төп фикере. Сөйләм төрләренең функцияләре: сурәтләү, хикәяләү, фикерләү. Текст анализы (аның темасы, төп фикере, билгеле бер стильгә каравы) |
| **Телнең функциональ үзенчәлекләре** | Телнең функциональ төрлелеге: гади сөйләм, функциональ стильләр һәм аларның жанрлары. |
| **Тел турында гомуми мәгълүмат** | Аралашу чарасы буларак тел. Татар теле — татар әдәби әсәрләр теле. Тел турындагы фән буларак лингвистика. Лингвистиканың төп бүлекләре (гомуми мәгълүмат).<br>Татар әдәби теле системасы. Тел һәм сөйләм тәңгәллеге. |
| **Фонетика һәм графика.** | Лингвистика бүлеге буларак фонетика. Тел берәмлеге буларак аваз.<br>Авазның мәгънә аеру функциясе.<br>Татар теленең сузык авазлар системасы.<br>Татар теленең тартык авазлар системасы. Шаулы тартыклар (яңгырау һәм саңгырау) һәм сонор тартыклар.<br>Иҗек. Басым. Интонация.<br>Аваз һәм хәреф тәңгәллеге.<br>Сүзгә фонетик анализ ясау.Кабатлау. |
| **Орфоэпия һәм орфография** | Орфоэпия нормалары төшенчәсе. Лингвистиканың бер бүлеге буларак орфоэпия. Әйтү вариантлары һәм басым. Орфоэпик кагыйдәләр күзлегеннән караганда, үз һәм чит кеше сөйләмен бәяләү. Орфоэпик сүзлекләр һәм көндәлек тормышта аларның кулланылышы.<br>Дөрес язу кагыйдәләре системасы буларак орфография. Сузыкларның һәм тартыкларның язылышы, ъ һәм ь билгеләренең кулланылышы.<br><br>Сүзләрнең бергә, аерым һәм сызыкча аша язылу очраклары.<br><br>Баш һәм юл хәрефләренең кулланылышы. Юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре.<br>Орфографик сүзлекләрне куллану очраклары. |

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| **Лексикология һәм фразеология** | Лексиканың өйрәнү предметы.<br>Лингвистиканың бер бүлеге буларак лексикология. Сүз – телнең төп берәмлеге. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер һәм күп мәгънәле сүзләр.<br>Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр.<br>Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.<br>Туган телнең синоним, антоним һәм омонимнары. Синоним, антоним, омонимнар сүзлеге.<br>Татар сүзләре һәм алынмалар.<br>Гомумкулланылыш сүзләре һәм кулланылышлары чикләнгән сүзләр.<br>Диалектизмнар, һөнәрчелек сүзләре, жаргоннар.<br>Актив һәм пассив лексика.<br>Искергән сүзләр һәм неологизмнар.<br>Тел гыйлеме фәненең бер бүлеге буларак фразеология. Фразеологик әйтелмәләр. Фразеологик әйтелмәләр сүзлеге.<br>Сүзгә лексик анализ ясау.Кабатлау. |
| **Морфемика һәм сүз ясалышы** | Морфемиканың өйрәнү предметы.<br>Тел турындагы фәннең бүлекләре буларак морфемика һәм сүз ясалышы. Сүзнең тамыры. Тамырдаш сүзләр. Төрле сүз төркемнәрендә сүз ясалышы үзенчәлекләре.<br>Сүз ясалышының үзенчәлекле ысуллары: морфемалар ярдәмендә сүз ясалышы, сүзләрне кушу, сүзнең бер сүз төркеменнән икенче сүз төркемнә күчүе һ.б.<br>Телнең иң кечкенә мәгънәле кисәге буларак морфеманы үзләштерү, аның мәгънәсе һәм яңа сүзләр, яңа сүз формасы ясалышындагы роле.<br>Сүз ясалыш ысуллары төшенчәсе.<br>Төрле сүзлекләр (сүз ясагыч, этимологик) куллану.<br>Морфемик һәм сүз ясагыч анализ.Кабатлау. |
| **Морфология** | Грамматиканың бер бүлеге буларак морфология. Татар телендә сүз төркемнәре системасы. Сүз төркемнәренең бүленеш принциплары.<br>Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре.<br>Модаль сүз төркемнәр: кисәкчә, ымлык, предикатив сүзләр.<br>Хәбәрлек сүз төркемнәре: бәйлек һәм теркәгеч.<br>Сүзнең лексик-грамматик, морфологик, лексик билгеләр буенча билгеле бер сүз төркеменә каравы. Сүз төркемнәренә морфологик анализ. |
| Синтаксис һәм пуктуация | Тел гыйлеме фәненең бер бүлеге буларак синтаксис. Синтаксик берәмлекләр буларак сүзтезмә һәм җөмлә.<br>Сүзтезмәләрнең төп төрләре, сүзтезмәдә баш һәм иярчен кисәкнең бәйләнеш ысулы.<br>Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре.<br>Җөмләдә баш һәм иярчен кисәкләр, аларның бәйләнеш ысуллары<br>Җөмләдә тиңдәш кисәкләр. Аерымланган кисәкләре булган җөмләләр.<br>Гади җөмлә төрләре: бер составлы һәм ике составлы, җыйнак һәм җәенке, тулы һәм ким, раслау һәм инкарь җөмләләр.<br>Кушма җөмлә төрләре: тезмә һәм иярченле кушма җөмләләр.<br>Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.<br>Күп иярченле кушма җөмлә.<br>Структура һәм мәгънә ягыннан иярченле кушма җөмлә төрләре.<br>Туры һәм кыек сөйләм.<br>Төрле сүзтезмә һәм җөмләләргә синтаксик анализ, аларны сөйләмдә дөрес куллану. |

| Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге |
|---|---|
| | Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан синтаксик синонимнарны куллану.<br>Татар телендә тыныш билгеләре.<br>Пунктуацион-мәгънәви өлеш.<br>Татар теленең пунктуация кагыйдәләре. Кабатлау. |
| Стилистика һәм сөйләм культурасы | Сөйләм стильләре (фәнни, рәсми, гади, әдәби, публицистик) һәм аларның үзенчәлекләре. Аудитория каршында чыгыш ясау: тема сайлау, максат һәм бурычны билгеләү, тел-сурәтләү чараларын сайлаганда, тыңлаучыларның кызыксынуларын исәпкә алу.<br>Телдән һәм язма сөйләм үзенчәлекләре.<br>Төрле жанр һәм стильдәге текстлар белән эшләү.<br>Текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. |
| **Сөйләм культурасы** | Кыскартылган сүзләрне дөрес әйтү. Орфоэпик сүзлекне файдалану. Сөйләмдә исем, сыйфат һәм фигыльләрне дөрес куллану.<br><br>Әдәби сөйләмдә исем, сыйфат һәм фигыльләрнең кулланылышын күзәтү.<br><br>Хәзерге татар теленең норматив сүзлекләре (орфоэпическ сүзлек, аңлатмалы сүзлек, орфографик сүзлек), аларның хәзерге татар әдәби телен үзләштерүдәге роле. |
| **Тел һәм мәдәният** | Татар халкының тарихы һәм мәдәниятенең, Россиядә яшәүче башка халыклар белән бәйләнешенең һәм урынының телдә чагылышы.<br>Татар сөйләм теленең кагыйдәләре һәм үзенчәлекләре.<br>Татар сөйләм этикеты.<br>Фольклор һәм әдәби әсәрләрдә, тарихи текстларда туган телнең милли-мәдәни берәмлеген билгеләү, лингвистик сүзлек ярдәмендә аларның мәгънәсен аңлату.<br>Татар сөйләмә теле кагыйдәләрен укуда һәм көндәлек тормышта куллану. |

## Тематик планлаштыру

## 5 класс

| № | Бүлек исеме | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Тел кешене дус итә | 1 |
| 2 | Алдагы сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | 10 |
| 3 | Фонетика һәм орфоэпия | 20 |
| 4 | Графика һәм орфография | 14 |
| 5 | Лексикология һәм сөйләм культурасы | 18 |
| 6 | Сүз ясалышы | 20 |
| 7 | Үткәннәрне кабатлау | 3 |
| 8 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 19 |
| 9 | Барлыгы | 105 |

**6 класс**

| № | Бүлек исеме | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Татарәдәби теле | 1 |
| 2 | Алдагы сыйныфта үткәннәрне кабатлау | 3 |
| 3 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре Исем | 12 |
| 4 | Фигыль | 31 |
| 5 | Сыйфат | 5 |
| 6 | Сан | 6 |
| 7 | Рәвеш | 7 |
| 8 | Алмашлык. | 8 |
| 9 | Аваз ияртемнәре | 2 |
| 10 | Хәбәрлек сүзләр | 2 |
| 11 | Бәйлек | 3 |
| 12 | Теркәгеч | 3 |
| 13 | Кисәкчә | 3 |
| 14 | Модаль сүзләр | 1 |
| 15 | Ымлыклар | 1 |
| 16 | Үткәннәрне кабатлау | 3 |
| 17 | Бәйләнешле сөйләм үткәрү | 13 |
|  | Барысы | 105 |

## 7 класс

| № | Бүлек исеме | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | Үткәннәрне искә төшерү.Гади җөмлә синтаксисы, тыныш билгеләре | 17 |
| 2 | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. | 33 |
| 3 | Җөмләнең модаль кисәкләре.Сүзләр тәртибе.Җөмләнең аерымланган кисәкләре | 18 |
| 4 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | 18 |
| 5 | Бер составлы җөмләләр.Кабатлау.. | 19 |

## 8 класс

| Бүлек саны | Бүлек исеме | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | Тел һәм тел гыйлеме | 1 |
| 2 | Үткәннәрне кабатлау | 4 |
| 3 | Туры һәм кыек сөйләм | 9 |
| 4 | Кушма җөмлә | 1 |
| 5 | Тезмә кушма җөмлә | 7 |
| 6 | Иярченле кушма җөмлә. | 11 |
| 7 | Иярчен җөмлә һәм аның төрләре. | 33 |
| 8 | Күп иярченле кушма җөмлә. | 11 |
| 9 | Катнаш кушма җөмлә. | 3 |
| 10 | Тезем. | 7 |
| 11 | Пунктуация. | 13 |
| 12 | Синтаксис буенча кабатлау | 5 |

## 9класс

| Бүлек саны | Бүлек исеме | Сәг.саны |
|---|---|---|
| 1 | Фонетика. Аваз һәм фонема. | 5 |
| 2 | Лексикология. | 10 |
| 3 | Морфология. | 4 |
| 4 | Синтаксик берәмлекләр. | 3 |
| 5 | Кушма җөмлә төрләре. | 16 |
| 6 | Әдәби сөйләм, аның стильләре. | 9 |
| 7 | Стилистика. | 7 |
| 8 | Синтаксик калькалар. | 2 |
| 9 | Сөйләм культурасы. | 7 |
| 10 | Тел – иҗтимагый күренеш. | 2 |
| 11 | Татар милли теленең барлыкка килүе. | 4 |
| 12 | Хәзерге татар әдәби теленең төп диалектлары. | 1 |
| 13 | Икетеллелек. | 1 |
| 14 | Тел гыйлеменең әһәмияте, төп бүлекләре. | 2 |
| 15 | Кабатлау. | 19 |
| 16 | Тестлар эшләү | 10 |